ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 374 от « 03 » 11 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны, документларны, материалларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 322 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, башкарма комитет җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2012 елның 20 июнендәге 1090 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны, документларны, материалларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 322 номерлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге びкарарга 1 нче кушымтаның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер

0000011432

электрон форма запросын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Гарызнамәчегә электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырны ачыклаганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон рәвештә хәбәр итү юлы белән хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов